| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|
| ПРИКАЗ | | БОЕРЫК |
| 04.10.2016 | Казан ш. | № 67 |

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварындагы № 3 боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең норматив-хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварындагы № 3 боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент), аны кушымта булып килүче яңа эчтәлегендә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә турыдан-туры дәүләт хезмәтен күрсәтүне тәэмин итүче башлык урынбасарларына, структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренә гамәли эшчәнлекләрендә Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянып эш итәргә.

3. Җыелма анализ бүлегенә Регламентны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Хокукый идарәнең юридик бүлегенә:

4.1. Бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4.2. Шушы Регламентта расланган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасы турында”гы 10.09.2010 № 729 карарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрергә.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгының беренче урынбасары И.Ф. Сафиуллины җаваплы итеп билгеләргә.

Башлык В.А.Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт
төзелешен күзәтү инспекциясенең
2012 елның 23 гыйнварындагы
№ 3 боерыгы белән (ТР ДТК инспекциясенең
04.10.2016 № 67 боерыгы төзәтмәсендә)
расланды

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте, Регламент).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: төзүче яки техник заказчы.

Мөрәҗәгать итүчеләр – дәүләт хезмәтен алучылар һәм аларның вәкаләтле вәкилләре.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Инспекция урнашкан урын: Казан ш., Зур Кызыл ур., 15/9 й.

Инспекциянең эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.30-17.30 сәгатьләрдә, җомга 8.30-16.30 сәгатьләрдә, төшке аш: 12.00-12.45 сәгатьләрдә.

Җәмәгать транспортында “КАИ” яки “Ирек мәйданы” тукталышына кадәр килергә кирәк:

- автобуслар №10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 83, 89, 91, 98;
- троллейбуслар № 2, 3, 5, 7.

Керү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ буенча.

1.3.2. Белешмә телефоннары:

237-91-87, 237-87-22 – Зур Кызыл ур., 15/9 й.;

518-92-81 – Декабристлар ур., 81Б.

Керү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ буенча.

1.3.3. Инспекциянең “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайты: http://gsn.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Инспекция биналарында урнаштырылган, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат 1.3.1, 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) бәян ителүче дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

2) "Интернет" челтәре аша:

Инспекциянең рәсми сайтында (http://gsn.tatarstan.ru);

Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https://uslugi.tatarstan.ru);

3) Инспекциягә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Инспекциягә язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле барлык мәгълүмат Инспекция аппаратының төзелеше тәмамланган объектларны кабул итү тәртибен күзәтү бүлегендә (алга таба – ТТОКИТК бүлеге) әзерләнә һәм Инспекциянең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла, аннан соң Инспекциянең рәсми сайтында урнаштыру өчен җыелма анализ бүлегенә тапшырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә таянып күрсәтелә:

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШрК) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2005, № 1 (1 б.), 16 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1994 елның 21 декабрендәге "Янгын куркынычсызлыгы турында" № 69-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 1994, № 35, 3649 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1995 елның 24 ноябрендәге "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" № 181-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 1995, №48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1999 елның 30 декабрендәге "Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында" № 52-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 10 гыйнварындагы "Әйләнә-тирәлекне саклау турында" № 7-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 27 декабрендәге "Техник җайга салу турында" № 184-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2002, № 52 (1б.), 5140 ст., 2005, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2007 елның 8 ноябрендәге "Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" № 257-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2007, № 46, 5553 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2008 елның 22 июлендәге "Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент" № 123-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2008, №30 (1 бүлек), 3579 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2009 елның 30 декабрендәге “Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент” № 384-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 384-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2010, №1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” № 210-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

РФ Президентының 2012 елның 7 маендагы “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүдә төп юнәлешләр турында” № 601 указы (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 1 февралендәге “Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында” № 54 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 54 карары) (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2006, №7, 774 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 26 декабрендәге “Аларны куллану нәтиҗәсендә “Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент” Федераль законы таләпләренең үтәлеше зарури нигездә тәэмин ителә торган илкүләм стандартларның һәм кагыйдәләр җыелмасының (мондый стандартларның һәм кагыйдәләр җыелмасының өлешләренең) исемлеген раслау хакында” № 1521 карары (Россия Федерациясенең Законнар җыелмасы, 2015, №2, 465 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 28 ноябрендәге “Татарстан Республикасында Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе турында” № ПУ-505 указы (“Республика Татарстан” газетасы, 2006, № 237-238, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабрендәге “Капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелешендәге башкарма документларның составына һәм аларны алып бару тәртибенә карата таләпләрне һәм эшләрне, конструкцияләрне, инженерлык-техник тәэмин ителеш челтәрләре өлешләрен таныклау актларына карата белдерелә торган таләпләрне раслау һәм кулланылышка кертү турында” №1128 боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007, № 9050 белән теркәлгән) (алга таба – Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1128 боерыгы) (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 2007, № 13, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабрендәге “Дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашырганда эшләрне рәсмиләштерү һәм алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” № 1130 боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 05.03.2007, № 9009 белән теркәлгән) (алга таба – Ростехнадзорның 26.12.2006 № 1130 боерыгы) (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 2007, № 13 кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2006 елның 26 декабрендәге “Дәүләт төзелеш күзәтчелеген тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү һәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентларның (нормаларның һәм кагыйдәләрнең), башка төрле норматив актларның, проект документларының таләпләренә ярашуы турындагы бәяләмәләрне бирү тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” № 1129 боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007, №9053 белән теркәлгән) (алга таба – Ростехнадзорның 26.12.2006, №1129 боерыгы) (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 2007, № 15, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең 2007 елның 12 гыйнварындагы “Капиталь төзелеш объектларының төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь төзекләндерелеше барышында башкарылган эшләрне исәпкә алуның гомуми һәм (яисә) махсус журналын алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында” № 7 боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 06.03.2007, № 9051 белән теркәлгән) (алга таба – Ростехнадзорның 12.01.2007, № 7 боерыгы) (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 2007, № 14);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 12 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе мәсьәләләре” № 622 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2007, № 43, 1707 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” № 880 карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 08.12.2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

**Төзүче** – үзенеке булган җир кишәрлегендә яисә башка хокук иясенең җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, аларны капиталь ремонтлауны, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкаруны, аларны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау өчен проект документларын әзерләүне тәэмин итүче (бюджет инвестицияләрен дәүләт (муниципаль) милектәге капиталь төзелеш объектларына гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), Атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, Галәм эшчәнлеге буенча “Роскосмос” дәүләт корпорациясе, дәүләти бюджетныкы булмаган фондларның идарә органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән очракларда килешүләр нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшырган) физик яки юридик зат;

**Техник заказчы** – төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән һәм төзүче исеменнән инженерлык эзләнүләрен башкару турында, проект документларын әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау турында шартнамәләр төзүче, аталган эш төрләрен башкаруга карата техник биремнәрне эшләүче, инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче, капиталь төзелеш объектларын төзүче, үзгәртеп коручы, капиталь ремонтлаучы затларга аталган эш төрләрен башкару өчен кирәкле метариалларны һәм документларны тапшыручы, капиталь төзелеш объектын эксплуатацияләүгә кертү өчен рөхсәт алу буенча кирәкле документларны имзалаучы, РФ ШрК каралган башка вазифаларны башкаручы, һөнәри нигездә гамәл кылучы юридик зат, яки физик зат. Төзүче техник заказчының РФ ШрК каралган вазифаларын мөстәкыйль дә башкарырга хокуклы.

**Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәгенең читтән торып эшләү урыны** – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итү һәм аларга тапшыру, аларны констультацияләү тәрәзәсе.

**Техник хата** – Инспекция тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, шушы белешмәләрне кертү аңа нигезләнеп башкарылган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (хәреф, язу хатасы, грамматик яки арифметик хата).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – Гариза) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә аңлашыла (27.07.2010 № 210-ФЗ Федераль законның 2 ст. 1 п.).

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпнең эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү | № 54 карарның 16 п., 26.12.2006 ел, № 1129 Ростехнадзор боерыгының 2 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе | № 622 карар |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тасвирлау | - төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) (1 кушымта);<br>- төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карар (алга таба – ярашлылык турында бәяләмәне бирүдән баш тарту) (2 кушымта) | № 54 боерыкның 19 п., 26.12.2006 ел, № 1129 Ростехнадзор боерыгының 29 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору чоры | Гаризаны теркәгәч ун эш көне эчендә.<br><br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган | № 54 боерыкның 19 п., 26.12.2006 ел, № 1129 Ростехнадзор боерыгының 29 п. |
| 2.5. Законнар һәм башка төрле норматив-хокукый | Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект | № 54 боерыкның 19 п. |

| | | |
|---|---|---|
| актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле, шул исәптән электрон рәвештәге документларның тулы исемлеге, аларны тапшыру тәртибе | документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмәне бирү турында гариза (рәвеше ирекле) (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә бирү турында гариза).<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында тамга белән, почта аша заказлы хат итеп.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре һәм Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны | Документлар таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан, шул исәптән электрон рәвештә алу тәртибе, аларны шушы документлар белән эш итүче дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшыру тәртибе | | |
| 2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норамтив-хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу килештерүне дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы гамәлгә ашыра торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итеп алудан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән туктату яки күрсәтүдән баш тарту өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| туктату яки күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | нигезләр юк | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башлка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм аны алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү алынмый | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәтен алу өчен кәгазьдә гариза тапшырганда, чират булганда – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтү вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының № 601 указының 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәне, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнар нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларын урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә: һаваны кондиционерлау системасы; янгынга каршы система; ТР Дәүләт интеграллаштырылган телекоммуникацияләр системасына тоташтырылган мәгълүмат киоскы; документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү):<br>- Казан ш., Декабристлар ур., 81Б адресы буенча урнашкан бинага мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр керә алсын өчен керә торган җирдә СП 59.13330.2012 “Инвалидларның үтемлеге” нигезендә пандус урнаштырылган.<br>- Казан ш., Зур Кызыл ур., 15/9 адресы буенча урнашкан бинага инвалидларга керү мөмкинлеген тәэмин итү максатларында керә торган җирнең сул ягындагы бина фасадында инвалидлар өчен персоналны чакырту төймәсе урнаштырылган. Аталган төймә аша сигнал биргәндә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә бинага кергәндә ярдәм күрсәтелә. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>1) кабул итү эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| исэптэн мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазифаи затлар белән хезмәттәшлек итү саны һәм аларның озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, шул исэптән мәгълүмати-коммуникатив технологиялəрдән файдаланып | 2) мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>3) мәгълүмат стендларында, "Интернет" челтəренең мәгълүмат ресурсларында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) документларны кабул итеп алу һәм тапшыру эшләре башкарыла торган биналардан инвалидларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм анын чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документларны кабул итеп алу һәм карап тикшерү вакытларын саклау;<br>2) дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>3) дәүләт хезмәткәре тарафыннан Регламентны бозуга карата прецендентлар (нигезле шикаятьләр) булу;<br>4) мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итеп алганда һәм аларга документларны тапшырганда чиратларның булмавы;<br>5) дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазифаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булмау.<br>Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алу өчен дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазифаи зат белән мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә хезмәттәшлек итүе күздә тотыла.<br>Ярашлылык турындагы бәяләмәне күпвазифалы үзәк аша, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәге читтән торып эшләү урыннары аша бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Инспекциянең рәсми сайтыннан (http://gsn.tatarstan.ru), | |

| | | |
|---|---|---|
| | Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru) алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә Инспекциянең http://gsn.tatarstan.ru сайтыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәге, күпвазифалы үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

### 3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү;

ярашлылык турында бәяләмә әзерләү һәм бирү яки мондый бәяләмне бирүдән баш тарту турында карар;

техник хатаны (язу, хәреф хатасын, гармматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелегенә карата блок-схема 5 кушымтада китерелә.

### 3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә Инспекциянең (Инспекциядәге территориаль органның) ТТОКИТК бүлегенә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итә.

3.2.2. Инспекция аппаратының (Инспекциядәге территориаль органның) ТТОКИТК бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәтен алуга бәйле башка мәсьәләләрдә, шулай ук, кирәк булганда, мөрәҗәгать итүчегә

ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, рәвеше буенча һәм ярашлылык турында бәяләмә бирүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләү, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

### 3.3. Ярашлылык турында бәяләмә әзерләү һәм бирү яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карар

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән (вәкаләтле вәкиле аша) кәгазьдә яки Интернет сайтыннан файдаланып электрон рәвештә ярашлылык турында бәяләмә бирү турындагы гаризаны Инспекциянең документлар белән тәэмин итү һәм контрольлек бүлегенә тапшыра. Гаризаны шәхсән (вәкаләтле вәкил аша) тапшырганда мөрәҗәгать итүче паспортын күрсәтә (әгәр дә гаризаны вәкаләтле вәкил тапшырса, ул вакытта паспорт һәм тиешле ышанычнамә күрсәтелә).

3.3.2. Документлар белән тәэмин итү һәм контрольлек бүлеге белгече:

документларны кабул итә һәм терки;

документларны кабул итү датасы һәм теркәлгән керү номеры турындагы тамга белән гаризаның күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра яки почта аша җибәрә;

гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында (алга таба – электрон хөкүмәт) терки;

гаризаны карап тикшерү өчен Инспекция башлыгына җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Инспекция башлыгына җибәрелгән гариза.

3.3.3. Инспекция башлыгы ярашлылык турында бәяләмә бирү турындагы гаризаны карап тикшерә һәм аны имзасын куеп Инспекциянең тиешле территориаль органына җитәкчелек итүче урынбасарына җибәрә.

Инспекция башлыгы урынбасары ярашлылык турында бәяләмә бирү турындагы гаризаны карап тикшерә һәм аны, имзасын куеп, Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлеге башлыгына һәм Инспекциянең тиешле территориаль органы җитәкчесенә җибәрә.

Территориаль орган җитәкчесе ярашлылык турында бәяләмә бирү турындагы гаризаны карап тикшерә һәм, имзасын куеп, аны территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген башкару өчен билгеләнгән җаваплы вазифаи затка (бердән артык җаваплы затлар билгеләнгәндә – билгеләнгән төркем җитәкчесенә) (алга таба – вазифаи зат) җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура ярашлылык турында гариза кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм вазифаи затка һәм территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә шушы Регламентта билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен җибәрелгән гариза.

3.3.4. Вазифаи зат ярашлылык турында бәяләмә бирү турындагы гаризаны карый һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру кысаларында формалаштырылган эшне (законнарнга туры килүен) тикшерү өчен территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көнендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: формалаштырылган, территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә җибәрелгән эш.

3.3.5. Территориаль органның ТТОКИТК бүлеге дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча формалаштырылган эшне, башкарма документларның составын һәм җыелмасын, аларның законнардагы таләпләргә җавап бирүен тикшерә.

Территориаль органның  ТТОКИТК бүлеге:

3.3.5.1. Формалаштырылган эшне Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлегенә тикшерү өчен җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач ике эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: формалаштырылган, Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлегенә тапшырылган объект эше.

3.3.6. Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлеге дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру, шул исәптән дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру процедурасы буенча формалаштырылган эшне башкарма документларының составы һәм җыелмасы, аларның законнардагы таләпләргә, шулай ук төзелешнең фактта тәмамлануына туры килүен  тикшерә.

Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлеге, формалаштырылган эшне карап тикшерү нәтиҗәсендә, Инспекция башлыгы өчен ярашлылык турында бәяләмә бирү турында карар яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен мәгълүмат әзерли.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагысы тәмамлангач ике эш көнендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Инспекция башлыгына җибәрелгән мәгълүмат.

3.3.7. Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлеге тарафыннан җиткерелгән мәгълүмат нигезендә Инспекция башлыгы ярашлылык турында бәяләмә бирү турында карар яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны территориаль орган җитәкчесенә җибәрә.

Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан кабул ителгән ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар төзүчегә яки техник заказчыга, дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан шушындый карарны кабул итү өчен нигез булган сәбәпләрне юкка чыгарганнан соң, ярашлылык турында бәяләмә бирү буенча яңадан мөрәҗәгать итүдә каршылык була алмый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Инспекция башлыгының территориаль органга тапшырылган карары.

3.3.8. Территориаль орган җитәкчесе Инспекция башлыгының ярашлылык турында бәяләмә бирү турындагы карарын алганнан соң Инспекция аппаратының финанс-икътисад контрольлеге бүлегендә җитди хисапнамә бланкын ала һәм рәсмиләштерү өчен территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура Инспекция башлыгы тарафыннан ярашлылык турында бәяләмә бирү карары кабул ителгән һәм территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә җитди хисапнамә бланкы тапшырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлеккә тапшырылган Башлык карары һәм җитди хисапнамә бланкы.

3.3.9. Территориаль органның ТТОКИТК бүлеге:

җитди хисапнамә бланкында ярашлылык турында бәяләмәне әзерли яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турындагы карарны рәсмиләштерә;

ярашлылык турында бәяләмә раслау турында яки мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карарны раслау турында әмернамә әзерли;

әмернамәне Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлеге башлыгы белән, административ тәҗрибә һәм өлешләп төзүне контрольлектә тоту бүлеге башлыгы, юридик бүлек башлыгы, территориаль орган җитәкчесе белән килештерә.

Вазифаи зат (төркем җитәкчесе) ярашлылык турындагы бәяләмәгә югарыда аталган барлык вазифаи затларның һәм территориаль орган җитәкчесенең имза салуын тәэмин итә.

Ярашлылык турында бәяләмә раслау турында яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында әмернамә Инспекция башлыгы яки аның урынбасары (Инспекция башлыгы вакытлыча булмый торганда) тарафыннан имзалана һәм Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлегенә тапшырыла.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлегенә тапшырылган, ярашлылык турында бәяләмә раслау турында яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында әмернамә.

3.3.10. Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлеге ярашлылык турында бәяләмә раслау турында яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында әмернамәне терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән ярашлылык турында бәяләмә раслау турында яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында әмернамә.

3.3.11. Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлеге җитди хисапнамә бланкында тутырылган ярашлылык турындагы бәяләмәнең беренче нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең кулына тапшыра яки җитди хисапнамә бланкында тутырылган ярашлылык турындагы бәяләмәне яки мондый бәяләмәне бирүдән

баш тарту турындагы карарны кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрә.

Ярашлылык турындагы бәяләмәнең икенче нөсхәсе Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлегендә кала.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кулга тапшырылган ярашлылык турында бәяләмә, яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында карар.

## 3.4. Техник хаталарны (язу, хәреф хаталарын, грамматик һәм арифметик хаталарны) төзәтү

3.4.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) ачыклаган очракта мөрәҗәгать итүче Инспекциягә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза (6 кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документ;

техник хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) барлыгы турында таныклый торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документ белешмәләрендәге техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яки вәкаләтле вәкиле аша кәгазьдә яки электрон рәвештә Интернет сайтыннан файдаланып тапшырыла.

3.4.2. Документлар белән тәэмин итү һәм контрольлек бүлеге белгече техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә терки һәм аларны территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергәннән соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә тапшырылган гариза.

3.4.3. Территориаль органның ТТОКИТК бүлеге белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документларга төзәтмәләр кертү максатларында шушы Регламентның 3.3.7-3.3.11 пунктларында каралган процедураларны башкара һәм яңадан рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкиленә) имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның чын нөсхәсен алып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта аша хат итеп (электрон почта ярдәмендә) территориаль органның ТТОКИТК бүлегенә техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның чын нөсхәсен тапшырган очракта документны кулга алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура  техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) ачыклаганнан соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган вазифаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләрне үз эченә алучы мөрәҗәгатьләрне тикшерүләрне, карауларны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрүдән гыйбарәт:

- эш башкарылышын алып бару, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлеше;
- документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә җавап бирүе;
- дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытларының, тәртибенең үтәлеше.

Тикшерүләрне үткәрү планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең билгеле бер мөрәҗәгате буенча) характерга ия.

4.2. Хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольлектә тоту Инспекция аппаратының ТТОКИТК бүлеге һәм җитәкчелек итүче Инспекция башлыгы урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыручы вазифаи затларның исемлеге Инспекциядәге структур бүлекчәләр турындагы нигезләмәләрдә, вазифаи регламентларда билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар РФ законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту Инспекция башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.5.  Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Идарә эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук аның вазифаи затларының, дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар түбәндәгеләрнең гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәрге тәртиптә шикаять кылу хокукына ия.

дәүләт гражданлык хезмәткәренекен – Инспекция башлыгына.

Инспекция башлыгының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырылырга мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да шикаять белдерергә хокуклы:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында караламган түләү таләп ителгәндә;

7) Инспекция, аның вазифаи заты дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тапшырылган нәтиҗәсендә җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

5.3. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында тапшырылырга, почта аша җибәрелергә, күпвазифалы үзәк аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталының Интернет-кабул итү системасы, Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша тапшырылырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү вакыты – аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазифаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуын яки мондый төзәтмәләрнң билгеләнгән вакыты бозылуны шикаять кылганда – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында.

5.5. Дәүләт хезмәтен алучыларның шикаятендә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның аталышы, карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителә торган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазифаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, аның вазифаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче шулар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, аның вазифаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмаган дәлилләр.

5.6. Шикаятькә анда бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге күрсәтелә.

5.7. Шикаять шәхсән яисә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан имзалана.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән язу хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук бүтән рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазифаи зат булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварындагы № 3 боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына карата 1 кушымта

(үрнәк)

ТР ДТК инспекциясе башлыгы әмернамәсе белән расланды

Эш номеры______________ “______” ________________ ел.

Нөсхә №______________ №___________________

_____________________________________

(җитәкче яисә аның вазифаларын башкаручы зат, яисә аның вәкаләтләре һәм вазифалар бүленеше кысаларында дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруга җитәкчелек итүче зат)

**ТӨЗЕЛГӘН, ҮЗГӘРТЕП КОРЫЛГАН КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫНЫҢ ТЕХНИК РЕГЛАМЕНТЛАРНЫҢ ҺӘМ ПРОЕКТ ДОКУМЕНТЛАРЫНЫҢ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ, ШУЛ ИСӘПТӘН КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫНЫҢ ЭНЕРГЕТИКА НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ҺӘМ ФАЙДАЛАНЫЛА ТОРГАН ЭНЕРГЕТИКА РЕСУРСЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛУ ҖАЙЛАНМАЛАРЫ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛҮЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ**

________________________ “____” ______________20___ ел.

(тутыру урыны)

Бу БӘЯЛӘМӘ бирелде_________________________________________________________

(төзүченең яисә техник заказчының аталышы,

_____________________________________________________________________________

дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның номеры һәм бирелгән датасы, ОГРН, ИНН,

_____________________________________________________________________________

почта реквизитлары, телефон/факс – юридик затлар өчен;

_____________________________________________________________________________

фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт белешмәләре, яшәгән урыны, телефон/факс – физик затлар,

_____________________________________________________________________________

шәхси эшмәкәрләр өчен (дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык номеры һәм бирелү датасы))

һәм шуны раслый, әлеге капиталь төзелеш объекты ___________________________________

(проект документлары нигезендә капиталь төзелеш объектының аталышы,

_____________________________________________________________________________

кыскача проект сыйфатламалары, төзелеш, үзгәртеп кору этабын сурәтләү,

___________________________________________________________________________

әгәр дә рөхсәт төзелешнең, үзгәртеп коруның бер этабына бирелсә)

түбәндәге адреста урнашкан:____________________________________________________

(почта яки төзелеш адресы)

_____________________________________________________________________________

Капиталь төзелеш объекты төзелешенә, үзгәртеп корылышына бирелгән рөхсәт_________

_____________________________________________________________________________

(номеры һәм бирелгән датасы, кем тарафыннан бирелгән, гамәлдә булу чоры)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә проект документларына карата уңай экспертиза бәяләмәсе (типик проект документларыннан яки анық типик проект документлары реестрына кертелгән модификациясеннән файдаланганлыкны күрсәтергә)______________________________________________

(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

______________________________________________________________________________

проект документларына карата уңай дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе, әгәр дә капиталь төзелеш объектының проект документлары дәүләт экология экспертизасына тиешле булса________________________________________________________

(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

____________________________________________________________________________

төзелешне, үзгәртеп коруны, шул исәптән мондый объектның конструктив һәм башка төрле ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагыла торган мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрнең башлануы___________________________________

(эшләрне башлау датасы)

төзелешне, үзгәртеп коруны, шул исәптән мондый объектның конструктив һәм башка төрле ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагыла торган мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрнең тәмамлануы________________________________

(эшләрне төгәлләү датасы)

Түбәндәге таләпләргә ҖАВАП БИРӘ:_____________________________________________

(техник регламентның, норматив-хокукый актларның,

______________________________________________________________________________

проект документларының аталышы, статьялары (пунктлары) күрсәтелә)

Бу БӘЯЛӘМӘНЕ бирү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:_________________________

(төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын

______________________________________________________________________________

тикшерү актының номеры, датасы һәм, үткәрелгән очракта,

______________________________________________________________________________

элек бирелгән күрсәтмәне тикшерү актының номеры, датасы)

______________________________ _____________ __________________________________

(вазифа) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Бәяләмә нөсхәсен алдым:______________________________________________________

(вәкиллек турындагы документ реквизитларын күрсәтеп, төзүче яки техник заказчы вәкиле тарафыннан тутырыла)

______________________________ _____________ __________________________________

(вазифа) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Искәрмә:

1) Бәяләмә төзелеше (үзгәртеп корылышы) тәмамланган объектны тикшерүдә (тикшерүләрдә) катнашкан дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнарының җаваплы вазифаи затлары тарафыннан имзалана;

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварындагы № 3 боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына карата 2 кушымта

(үрнәк)

ТР ДТК инспекциясе башлыгы әмернамәсе белән расланды

Эш номеры______________ “______”________________ ел.

Нөсхә №______________ №___________________

____________________________________

(җитәкче яисә аның вазифаларын башкаручы зат, яисә аның вәкаләтләре һәм вазифалар бүленеше кысаларында дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруга җитәкчелек итүче зат)

**ТӨЗЕЛГӘН, ҮЗГӘРТЕП КОРЫЛГАН КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫНЫҢ ТЕХНИК РЕГЛАМЕНТЛАРНЫҢ ҺӘМ ПРОЕКТ ДОКУМЕНТЛАРЫНЫҢ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ, ШУЛ ИСӘПТӘН КАПИТАЛЬ ТӨЗЕЛЕШ ОБЪЕКТЫНЫҢ ЭНЕРГЕТИКА НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ҺӘМ ФАЙДАЛАНЫЛА ТОРГАН ЭНЕРГЕТИКА РЕСУРСЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛУ ҖАЙЛАНМАЛАРЫ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШ ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛҮЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ БИРҮДӘН БАШ ТАРТУ ТУРЫНДА КАРАР**

__________________________ “______”_______________20___ ел

(тутыру урыны)

Бу КАРАР бирелде:___________________________________________________________

(төзүченең яисә техник заказчының аталышы,

________________________________________________________________________________

дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның номеры һәм бирелгән датасы, ОГРН, ИНН,

________________________________________________________________________________

почта реквизитлары, телефон/факс – юридик затлар өчен;

________________________________________________________________________________

фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт белешмәләре, яшәгән урыны, телефон/факс – физик затлар,

________________________________________________________________________________

шәхси эшмәкәрләр өчен (дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык номеры һәм бирелү датасы))

төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында БӘЯЛӘМӘ бирүдән баш тарту турында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварындагы № 3 боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына карата 3 кушымта

(үрнәк)

ӘМЕРНАМӘ КҮРСӘТМӘ

_____________ Казан ш. №_________

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 01 февралендәге “Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында” № 54 карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 12 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе мәсьәләләре” турында № 622 карарына, 26.12.2006 № 1129 Ростехнадзор боерыгы таләпләренә, Инспекциянең 2012 елның № 3 боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына таянып һәм төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын тикшерү турында ___________________________№_________актына нигезләнеп, ___________________________ ________________ адресы буенча урнашкан, төзелеш тәмамланган _________________________________ объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә **Р А С Л Ы Й М**.

Башлык урынбасары ______________________

**Искәрмә:** әмернамәнең икенче ягы ТТОКИТК бүлеге башлыгы, административ тәҗрибә һәм өлешләп төзүне контрольдә тоту бүлеге башлыгы, юридик бүлек башлыгы, территориаль орган җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2012 елның 23 гыйнварындагы № 3 боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына карата 4 кушымта (белешмә)

## Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазифаи затларның реквизитлары

### Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе


| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгы Кудряшов Василий Александрович | (843) 237-91-87 | Vasiliy.Kudryashov@tatar.ru |
| Инспекция башлыгының беренче урынбасары Сафиуллин Илфарт Фәтхерислам улы | (843) 237-91-87 | Ilfart.Safiulli№@tatar.ru |
| Инспекция башлыгы урынбасары Гаянов Рафаил Гатаулла улы | (843) 518-48-99 | Rafail.Gayanov@tatar.ru |
| Инспекция башлыгы урынбасары Фатыйхов Линар Замир улы | (843) 237-91-87 | Li№ar.Fatyhov@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Сибгатуллин Илдар Нурзадә улы | (843) 264-77-16 | Ildar.Sibgatulli№@tatar.ru |
| Юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру буенча бүлек башлыгы Азин Юрий Николаевич | (843) 264-77-24 | Yuriy.Azi№@tatar.ru |

## Блок-схема

| Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Мөрәҗәгать итүче | Документлар белән тәэмин итү һәм контрольлек бүлеге | Инспекция башлыгы | Башлык урынбасары, территориаль орган җитәкчесе | Инспекция аппаратының төзелеше тәмамланган объектларны кабул итү тәртибен күзәтү бүлеге | Инспекция башлыгы урынбасары | Мөрәҗәгать итүче |



Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының таләпләренә, шул исәптән капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэминителеш таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына карата

**6 кушымта**

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
башлыгына
кемнән:___________________________

Техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза

_____________________________________________________________________ дәүләт
(хезмәтнең аталышы)
хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Болай дип язылган:_____________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Дөрес белешмәләр:_____________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләре кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны шушы рәвешле җибәрүне сорыйм:

электрон документ җибәрү юлы белән, түбәндәге E-mail адресына:________;

кәгазьдә таныкланган күчермәсе рәвешендә, түбәндәге адрес буенча почта аша: _______________________________________________________.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, тәгаенләү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, блок кую, шәхси белешмәләрне юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкаруга) карата, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар тарафыннан алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем исемемнән эш йөртүче затның ризалыгын раслыйм.

Хәзергесе белән раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем исемемнән эш йөртүче затның шәхесенә кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру чорына әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес белешмәләрне үз эченә ала.

_____________ ________________ ( ________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.)